ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАТАР ЧАЛЛЫСЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ
ТАТАР ЧАЛЛЫСЫ АВЫЛЫНДА ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

2020 елның 28 ноябреннән № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы белән Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Татар Чаллысы авыл җирлеге гражданнары җыены КАРАР БИРӘ:

1. 2021 елда Менделеевск муниципаль районының Татар Чаллысы авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Үзара салым акчаларын түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

**- Авыл җирлеге территориясен төзекләндерү (печән чабу)**

**- Юлны вак таш белән җәю (вак таш сатып алу һәм китереп җиткерү);**

**- Татар Чаллысы авылы сууткәргеч челтәрләрен ремонтлау (коеларны, суүткәргеч челтәрләрне алмаштыру һәм урнаштыру)**

**- Мохначев урамындагы газ конденсатын урнаштыру (янгын куркынычсызлыгын саклау өчен)**

**- топограф-геодезик эшләр («Татар Чаллы авылы янындагы буада капиталь ремонт» объекты)**

3. Узган еллардагы акчаларның калган өлешен юлларны вак таш белән җәю (вак таш сатып алу һәм китереп җиткерү) эшләре төрен үтәү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә куллану

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырыпчыгарырга һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http://mendeleevsk.tatarstan.ru «Татар Чаллы авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Татар Чаллысы авыл җирлеге
башлыгы Т.П. Кузнецова.